**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Аксар авыл җирлегенең Бүре-Сарай торак пунктында**

2023 елның 13 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлегендә халык җыены, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлегендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Аксар авыл җирлеге Бүре-Сарай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
-урам утларын көйләү;
-чишмәне ремонтлау һәм төзекләндерү;
- янгын сүндерү өчен су резервуарларының краннарын буяу һәм ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Аксар авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Аксар авыл җирлеге башлыгы _______________ Ю.И.Гильманов